РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 123

2018 елның 26 июне

# Түбән Кама шәһәренең торак-коммуналь хуҗалык объектларын 2018-2019 еллар ягу чорына әзерләү турында

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын 2018-2019 еллар ягу чорында тотрыклы һәм ышанычлы эшләүгә вакытында әзерләү максатыннан, карар бирәм:

1. Расларга:

1.1. 2018-2019 еллар ягу сезонына әзерлек буенча штаб составын (1 нче кушымта).

2. «Түбән Кама ТЭЦ» ПТК-1 «ТГК-16» ААҖ филиалына (Олюнин С.Ю.), «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ (Юмангулов А. Р.), «Татэнерго»-«Түбән Кама җылылык челтәрләре» АҖ филиалына (Гәрәев А.Ф.), «Түбән Кама шәһәре торак-коммуналь һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесенә (Перепелов П.Д.), «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖга (Нуртдинов И.Н «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы») челтәрле компания» ҖЧҖга (Огурцов С.В.), «Түбән Кама газ» ЭПУга (Токарев А.С.):

- атна саен 2018-2019 еллар ягу чорына торак фонды, социаль-көнкүреш билгеләнешендәге, коммуналь энергетика, суүткәргеч-канализация һәм газ хуҗалыгы объектларының әзерлек барышын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- 2018 елның 1 сентябренә кадәр узган ягу чорында табылган кимчелекләрне бетерү белән бина һәм инженер системаларының, челтәр һәм корылмаларның ышанычлы эшләвен арттыру буенча расланган йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итәргә; әзерлек паспортларын рәсмиләштереп, торак-коммуналь хуҗалык объектларын кышка әзерләүне төгәлләргә;

- кышкы шартларда торак биналарны һәм инженер объектларын эксплуатацияләү кагыйдәләренә эксплуатацияләү һәм ремонтлау персоналына инструктаж үткәрү һәм өйрәтү;

- атна саен «Түбән Кама шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесенә билгеләнгән форма буенча 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлек буенча йөкләмәләрне үтәүнең барышы турында мәгълүмат бирергә (2 нче кушымта).

3. Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җылылык чыганакларын эшләп чыгарылган җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары белән тәэмин

итәргә һәм 2018 елның 1 ноябренә кадәр 2018-2019 еллар ягу чорында эшкә әзерлек паспортларын алырга.

4. «Түбән Кама шәһәренең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының берләштерелгән диспетчерлык хезмәтенә 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлек буенча йөкләмәне үтәүнең барышы турында, хисаптан соң килә торган айның 1 числосына кадәр срокта билгеләнгән форма буенча гомумиләштерелгән мәгълүмат бирергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.И. Баландин

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының
2018 елның 26 июнендәге
123 номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

2018-2019 еллар ягу чорына әзерлек буенча штаб
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Баландин<br>Денис Иванович | - | Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, штаб башлыгы (килешенү буенча); |
| Перепелов<br>Павел Дмитриевич | - | «Түбән Кама шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» МУП директоры, штаб башлыгы урынбасары. |
| Штаб әгъзалары: | | |
| Нуртдинов<br>Ильдар Наил улы | - | «Сууткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Салаватов<br>Айрат Ринат улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең Түбән Кама территориаль бүлеге башлыгы (килешенү буенча); |
| Ихсанова<br>Наиля Нариман кызы | - | Түбән Кама зона торак инспекциясе башлыгы (килешенү буенча); |
| Красильников<br>Василий Борисович | - | «Татэнергосбыт» ААҖ филиалының Кама бүлеге башлыгы (килешенү буенча); |
| Гәрәев<br>Айдар Фердинант улы | - | «Татэнерго» - «Түбән Кама җылылык челтәрләре» АҖ филиалы директоры; |
| Логинова<br>Светлана Николаевна | - | «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Огурцов<br>Сергей Владимирович | - | «Түбән Кама электр челтәрләре филиалы» челтәр компаниясе» ААҖ директоры (килешенү буенча); |
| Слободюк<br>Константин Петрович | - | Түбән Кама муниципаль районы буенча ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе башлыгы (килешенү буенча). |

Татарстан Республикасы Түбән Кама
шәһәре башкарма комитетының
2018 елның 26 июнендәге
123 номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

_________________________ буенча
2018-2019 еллар ягу сезонына
торак-коммуналь хуҗалык объектларын әзерләү буенча
ЙӨКЛӘМӘ

| Күрсәткечләр | Юллар саны | Үлчәү берәмлеге | Барлыгы | Әзерлек буенча йөкләмә | Хисап чорына кышкы шартларда эшләү өчен әзерләнгән | Капиталь ремонт, реконструкция, алыштыру эшләре башкарылды | Йөкләмә үтәлеше % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Торак фонды - барлыгы : | 1 | мең бер. | | | | | |
| | 2 | мең.кв.м | | | | | |
| Шул исәптән | | | | | | | |
| муниципаль | 3 | мең бер. | | | | | |
| | 4 | мең бер. | | | | | |
| дәүләт | 5 | мең бер. | | | | | |
| | 6 | мең бер. | | | | | |
| хосусый | 7 | мең бер. | | | | | |
| | 8 | мең бер. | | | | | |
| Котельныйлар- барлыгы | 9 | бер. | | | | | |
| егәрлек | 10 | Гкал. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 11 | бер. | | | | | |
| егәрлек | 12 | Гкал. | | | | | |
| Барлык милек төрләре буенча җылылык челтәрләре | 13 | км. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 14 | км. | | | | | |
| Милекнең барлык төрләре буенча тузган җылылык челтәрләре (2 торба исәплләгәндә) | 15 | км. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 16 | км | | | | | |
| Җылылык насос станцияләре | 17 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 18 | бер. | | | | | |
| Милекнең барлык төрләре буенча үзәк җылылык пунктлары (ЦТП) | 19 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 20 | бер. | | | | | |
| Милекнең барлык төрләре буенча су алу | 21 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 22 | бер. | | | | | |
| Милекнең барлык төрләре буенча суүткәргеч насос станцияләре, | 23 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 24 | бер. | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Суүткәргечнең чистарту корылмалары, милекнең барлык төрләре буенча | 25 | бер. | | | | | |
| Үткәрү сәләте | 26 | т.м3/тәүл. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 27 | бер. | | | | | |
| Үткәрү сәләте | 28 | т.м3/тәүл. | | | | | |
| Су челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча | 29 | км. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 30 | км | | | | | |
| Тузган су челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча: | 31 | км | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 32 | км | | | | | |
| Канализация насос станцияләре, милекнең барлык төрләре буенча | 33 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 34 | км | | | | | |
| Канализация чистарту корылмалары, милекнең барлык төрләре буенча | 35 | бер. | | | | | |
| Үткәрү сәләте | 36 | т.м3/тәүл. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 37 | ед. | | | | | |
| Үткәрү сәләте | 38 | т.м3/тәүл. | | | | | |
| Канализация челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча | 39 | км | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 40 | км | | | | | |
| Тузган канализация челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча | 41 | км | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 42 | км | | | | | |
| Электр челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча | 43 | км | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 44 | км | | | | | |
| Тузган электр челтәрләре, милекнең барлык төрләре буенча | 45 | км | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 46 | км | | | | | |
| Барлык милек төрләре буенча трансформатор подстанцияләре | 47 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 48 | бер. | | | | | |
| Милек формасына карамастан, механикалаштырылган җыештыру өчен махсуслаштырылган машиналар | 49 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 50 | бер. | | | | | |
| Урам-юл челтәре, милекнең барлык төрләре буенча | 51 | мең кв.м | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 52 | мең кв.м | | | | | |
| Милек формасына карамастан, күпер корылмаларын (транспорт һәм җәяүлеләр күперләре һәм юлүткәргечләр, торбалар, виадуклар, акведуклар) әзерләү | 53 | бер. | | | | | |
| Шул исәптән муниципаль оешмаларның ТКХ | 54 | бер. | | | | | |

«_____»______________20__ел.
Башкаручы:________________________
Вазыйфа ________________________
Телефон № ________________________